**Басыйрова Э. «Акча эшлисең килсә, дин уйлап чыгар»**

**Рубрика: Вәзгыять/ Заман**

**Тренинглар турында кем нәрсә уйлый?**

**Зөлфия Ибраһимова, доцент, фәлсәфә фәннәре галиме:**

– «Тренинг» – кешенең белемен үстерү максаты белән формалашкан ысул. Ул эшчәнлек актив рәвештә оештырыла. Димәк, күренекле, сәләтле шәхесләр аны барлыкка китерә. Бу караш, билгеле, идеалыбызда яши. Ә тормышта? XX гасырның азагында «тренинг» хәрәкәте җәмгыятьтә күренә башлады. Минемчә, иң эчкерсез һәм уңышлы тренинглар безнең зур укытучыларыбыз В.Ф. Шаталов һәм Ш. А. Амонашвили; Е. Н. Ильин һәм Н.Н. Палтышев, С.Н. Лысенкова һәм М.П. Щетинин, И.П. Волков һәм И.П Иванов, В. А. Караковский һәм Б. П. Никитин тарафыннан үсеп чыкты. Совет мәктәбе әле бернинди **кризис** сүзен тоймаса да, югары дәрәҗәдә кызыклы тәҗрибәләр үткәрелә, эзләнүләр алып барыла иде. Бәлки бу олпат, кызыклы шәхесләр, булачак авырлыкларны сизеп, яңа карашлар тәкъдим иткәндер. Мин үзем дә студент чагында мондый очрашуларга, лекцияләргә дәртләнеп йөрдем. Мәсәлән, шундый бер лекция ЭВМ заводы конференция залында үтте. Зал шыгрым тулы, энә төртерлек тә урын юк. Онытылмаслык мизгелләр! Еллар узгач иң борчулы сорау туа: бу рухи казанышлар кая югалды? Ә бит болар безнең җәмгыяви үсешебезне раслый торган күренешләр иде. Мәктәп һәм җәмгыять үзләренең рухи хәзинәләрен югалтты дип әйтәсем килми. Шул ук вакытта безгә сиздермичә генә идеология кыйммәтләре үзенең көчен билгесез яңа карашларга алыштыра башлады.

Заманча тренинг – ул аерым, иҗади, һөнәри эшчәнлек. Аның төп максаты – булган белемне, билгеле тәҗрибәгә таянып, кешегә тапшыру, теоретик һәм практик файдалану. Димәк, бу белем төре – актуаль. Гамәлдә, тренинг күренеше каршылыклы. Миңа калса, алар безнең урта һәм югары белемнең

йомшак, зәгыйфь якларын бик ачык күрсәтә. Рухи яшәештә бушлык озак тора алмый. Ә мәгърифәтчелек үзенең вазыйфаларын заманча аңлыймы, үтиме? Бәлки, аның тәкъдимнәре, белемнәре заман таләпләренә туры килмидер? Читтән безгә яңа офыклар ачарга әзер торган кешеләр – тренинг уздыручылар әлеге бу сорауларга җавап бирергә ышандыра. Афәрин! Бу укытучыларга ышаналар, тәнкыйть хупланылмый. Тренингта кеше нинди искитмәле яңалык ишетә? Анда дәвалану методикасы, балаларны тәрбияләүгә яңа прогрессив караш һ.б. яңгырый. Җаныгыз ни тели – бөтенесе бар.

Ышанам, бу очрашулардан соң кемдәдер яңа фикерләр туа, ул үзенә көч туплый. Әмма хакыйкать күп очракта берничә юл, караш таләп итә. Аның өчен күп укырга, уйланырга, бәхәсләшергә, эшләргә, ялгышырга кирәк. Ә тренинг сиңа туры һәм ачык юл күрсәтә янәсе. Ул сиңа килешәме, файдалымы, куркыныч тудырмыймы? Моны кем төгәл тикшерә һәм ачыклый ала? Анда төрле кешенең ихтыяҗына универсаль дәва, рецепт бирелә. Кайда соң әле кешенең тәнкыйть күзе? Ә ул шәхескә үз вакытында тәрбия һәм белем **аша** бирелмәгән булса? Шул исәптән карасаң, тренинг – кешене тиз һәм уңайлы максатка китерә торган бер ысул. Чөнки ул үз жанр закончалыкларына буйсына: кыска вакытта үтә, түләүле әлбәттә, калган карашларны катгый рәвештә сызып ташлый.

Дөрес, XX гасыр белем алу традициясен кискен рәвештә үзгәртә. «Тере» белем тамашалы, психологик чаралар куллана. Алар рәтендә тренинг та зур популярлык казана. Чөнки, белемгә омтылу – күркәм күренеш. Дөнья үзенең киңлегеннән, тар бер тугандашлар түгәрәгенә әйләнә. Кеше читләшүдән арынып, яңа социаль бердәмлек башкара. Аның янәшәсендә – охшашлы ихтыяҗлар белән килгән кешеләр. Нинди җаваплылык, нинди югары әхлакый дәрәҗә, нинди белем камиллеге булырга тиеш тренинг алып баручы кешедә! Аны тагы да үстергән, тәнкыйть сәләтен көчәйткән,

гомумкешелек сыйфатларын уяткан укытучыны тыңлыйсы килә! Шуңа да бәлки, кулга китап тотып, йоклаган фикеремне уяту хәерлерәктер?

Тренингларның киң колач җәюе яңа сәяси ирекле шартлар белән дә бәйле. Кызганыч, бу плюрализм җимешләре тормышка бихисап каршылыклы, файдасыз, психологик яктан куркыныч, рациональ яссылыкта буш, мәгънәсез «укытучыларны» барлыкка китерде. Ә бу күренешләрне социаль, сәяси, мәдәни яктан карасаң, безнең **кризис** халәтенә эләккәнебез ачыла. Чиксез иреклектә бары тик прогрессив, яңа карашлар хөкем сөрергә тиеш, тик гамәлдә бу кешеләрне нинди катлаулы һәм ялгыш юнәлешләргә алып кереп китте. Идеологик вакуум чорында мондый күренеш табигый.
Бүгенге җәмгыятьтә рухи яктан имгәнгән, күңелләре авыру кешеләрнең күп булуын яңа идеологиянең бик озак формалашуы белән аңлатыр идем. Кеше бу дөньяда үз тамырларын бик көчле җәяргә тиеш. Аны рухи ризыктан мәхрүм итәргә ярамый. Кешене мәдәни хәзинәдән аерсаң, ул үзенә ясалма таяныч уйлап чыгара. Кызганыч, икътисадый-сәяси шартлар тискәре, негатив роль уйный. «Бөек үзгәрешләр» чорында яшәгән кеше идеологик бушлыкта югалып калып, үзенең рухи сәламәтлеген җуйды.

Эволюциянең уңайлы казанышлары һәр буында, гасырда яңадан җәмгыяви тәҗрибә, хәтер ярдәмендә саклана. Әгәр дә бу механизм эшләми икән, без кыргый, вәхши дәрәҗәдә калган кешене очратабыз. Аңа бернәрсә дә йогынты ясамаган. Шул исәптән, ярымшәрә килеш урамга чыгып басалар, кеше кыяфәтен югалтканын сизмиләр. Бу мәсьәлә кешенең иманыннан гына тормый. Кеше бит дөньяви мәдәният кыйммәтләре белән дә бәйле. Соңгысы адәм баласының дини тәрбиясе белән бердәмлектә яши.

Кайда туып үсә андый затлар? Безнең арада. Аларның рухи яктан зәгыйфьлеге галәм киңлегеннән килеп чыкмаган. Мәктәптә битараф яисә ялкау укытучы кулыннан, гаиләдә бәхетсез, мәгънәсез ата-анадан ирекка очалар да, көчле җил белән аларны «аңлаган», «җәлләгән» кешеләр кулына

килеп кабалар. Мондый яңа «пәйгамбәрләр» тормышның төрле катлаулы сорауларына дөрес җавабын белә. Иң куркынычы – алар арасында чын мәгънәдә укымышлы шәхесләр дә очрый. Үзләренең һөнәри сыйфатларын демагогик, ялганлы методикалар **аша** шикле максатларга буйсындыралар: төрле юллар **аша** дан казанырга омтылалар, акчага сатылалар. Мин берәүне дә бердәнбер идеология чорына әйдәмим. Сүз ирегeн югары һәм һичшиксез гомумкешелек казанышы итеп күрәм. Әмма җәмгыятьнең читтә калырга хакы юк. Аерым тренинг юнәлешләре җәмәгатьчелек тарафыннан бәяләнергә тиеш. Әлегә алар мөстәкыйль юл белән бара, бу өлкәдә гражданнар җәмгыяте күп очракта битараф. Кешенең профессиональ һәм иҗади эшчәнлегенә гуманистик күзлектән карау зарур. Җәмгыять үзенең тарихи урынын һәм дәрәҗәсен нык тотарга тиеш.

http://idel-tat.ru/akcha-eshlise-kils-din-ujlap-chygar/